**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 17 февраль № 94

г. Казань

Тукай муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, Тукай муниципаль районының Иштирәк авыл җирлеге башкарма комитетының Тукай муниципаль районында урнашкан, Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегенең муниципаль милкендә булган 9,2663 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлекләрен түбәндәге кадастр саннары белән кадастр паспортында күрсәтелгән чикләрдә, энергетика объектлары урнаштыру максатларында, сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Мәйданы, гектар |
|---|---|
| 16:39:061001:251 | 0,0409 |
| 16:39:061001:253 | 2,655 |
| 16:39:061001:250 | 0,0133 |
| 16:39:061001:247 | 0,3141 |
| 16:39:061001:236 | 0,1037 |
| 16:39:061001:235 | 1,2455 |
| 16:39:061001:234 | 4,8729 |
| 16:39:061001:248 | 0,0209 |
| Барлыгы | 9,2663. |

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\94.docx